Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«14» ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 12 нче һәм 14 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бикүле авылындагы 3нче номерлы зират коймасын ремонтлау һәм карап тоту;

- Бикүле торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау;

(грунт-вак таш катнашмасы һәм вак таш җәю, сатып алу, ташу, җәю)» мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 407 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 229 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 211 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 18 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бикүле авылындагы 3нче номерлы зират коймасын ремонтлау һәм карап тоту;

- Бикүле торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау;

(грунт-вак таш катнашмасы һәм вак таш җәю, сатып алу, ташу, җәю)» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова